**Азнакай муниципаль районы**
**Югары Стәрле авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Югары Стәрле авылы № 96-63 "19"сентябрь 2023 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Советының 2016 елның 1 июнь № 32-18 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлегенең муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (19.09. 2017 № 65-40, 15.01.2018 № 85-53, 28.12. 2019 №155-94, 17.04. 2020 № 169-103, 27.09. 2021 № 37-21,07.04.2023 №85-53 карарлар редакциясендә)

«Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 24 июлендәге 345-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Югары Стәрле авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Советының 2016 елның 1 июнь № 32-18 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлегенең муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (19.09. 2017 № 65-40, 15.01.2018 № 85-53, 28.12. 2019 №155-94, 17.04. 2020 № 169-103, 27.09. 2021 № 37-21,07.04.2023 №85-53 номерлы, карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 10 бүлекнең 1 пунктында:

а) алтынчы абзацта «, газ бүлү челтәрләре, газ куллану челтәрләре һәм мондый челтәрләр объектлары» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле яңа сигезенче абзац белән тулыландырырга:

«- газ бүлү челтәрләренә, газ куллану челтәрләренә һәм мондый челтәрләр объектларына карата «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында»гы 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 30.5 статьясында каралган башка шартлар;»;

в) сигезенче, тугызынчы абзацларны тугызынчы, унынчы абзацлар дип санарга.

2. Әлеге карар 2023 елның 23 октябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Л.С. Сабирҗанова